*…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!*

# Караш

**1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.**
**№ 3 2018. февраль**
**«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге**

# ТЕЛ ДИГӘН ДӘРЬЯ БАР...

## 21 нче февраль – Халыкара Туган тел көне уңаеннан махсус чыгарылыш

### ТАРИХ БИТЛӘРЕНӘ КҮЗ САЛСАК...

Дөньяда 7000 гә якын тел бар. Шуларның 83е киң таралган. Ә 383 тел бөтенләй юкка чыгарга мөмкин. Мәсәлән, Африка урманнарында яшәүче ючи кабиләсе телендә 5 кеше генә сөйләшә.

Һәр халыкның туган теле – аның мәдәнияте, тарихи көзгесе. Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор.

Бүген - 21 нче февраль – Халыкара туган тел көне. Туган теле белән горурланган һәркем өчен әлеге көн зур бәйрәм.

***2000 нче елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы, ЮНЕСКО инициативасын хуплап, күптеллелекне яклау йөзеннән 21 нче февральне “Халыкара туган тел көне” итеп үткәрү турында карар кабул итте. Нәкъ 21 нче февраль көненең сайлап алынуы очраклы түгел. 1952 нче елда бу көнне ул чагындагы Пакъстанда бенгал теленә дәүләт статусын бирүне яклап көрәшүче 5 студент һәлак була.***

*Туган оясыннан аерылган кош*
*Канатына мәңге ял тапмый.*
*Туган телен яратмаган кеше,*
*Башкаларның телен яратмый.*

***ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ көне уңаеннан безнең мәктәптә дә бик күп чаралар уздырылды: әлеге көнгә багышланган сыйныф сәгатьләре, Герой шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган әдәби –музыкаль кичә, Әлифба бәйрәме, тел гыйлеменең кызыклы күренешләренә багышланган шаяннар һәм тапкырлар бәйгесе. Бер сыйныф та читтә калмады...***

Родной язык. Он впитан с молоком.
Звучит как музыка, нам сердце услаждая
В международный день родного языка
На языке родном тебе мы пожелаем:
Люби язык, храни на день и на века!
Не забывай мелодию родного языка.



**Русский язык- это не сухая наука, хотя и серьёзная. Однако и о серьёзном можно говорить с элементами шутки, занимательности. Предлагаем вам различные загадки, которые продемонстрируют вам, как богат, выразителен и интересен русский язык.**

**Отгадайте шуточные загадки:**

Что стоит посредине земли?
Что находится в начале книги?
Что мы слышим в начале урока?
В каком слове буква «я» находится 7 раз?
В каком слове 40 гласных?
Какие два местоимения мешают движению транспорта?
Какие три местоимения самые чистые?
Какой корень в слове «вынуть»

*( буква «м») ( Буква «к») ( Букву «у») («семья) (сорока) (я-мы) (вы-мы-ты) (нет корня)*

**Шарада – это загадка, в которой загаданное слово делится на несколько составных частей, каждая из которых представляет собой отдельное слово.**

1) На первом стоит часовой
Второе в лесу зеленеет.
На целое, только стемнеет,
Ты ляжешь – и кончен твой день трудовой.

2) Первое –нота, второе – тоже,
А целое- на горох похоже.

3) Первый слог – китайский напиток,
Второй – название буквы,
А целое – птица.

(Пост- ель) (фа- соль) (Чай-ка)

## Без – татарлар, телебез татар теле, мөстәкыйль төзек кагыйдәле камил тел ул.

**(Каюм Насыйри)**

...Эзоп, имештер, философ Ксанфның колы булган. Бервакыт Ксанф кунаклар чакырырга уйлаган һәм Эзопка табынга иң яхшы нәрсә пешереп китерергә боерган. Эзоп ит базарына барып тел сатып алган һәм аннан өч төрле ризык хәзерләгән. Ксанф, бу хәлгә гаҗәпләнеп, Эзоптан сораган:

–Ни өчен син һаман тел генә китерәсең?- дигән.

–Син миңа иң яхшы нәрсә алырга куштың,– дигән Эзоп җавап итеп.-

Ә дөньяда телдән дә яхшырак нәрсә бар ?! Тел ярдәмендә шәһәрләр төзелә, халыкларның культурасы үсә. Тел ярдәмендә кешеләр бер-берсе белән аңлашалар, шатлык-сөенечләрен уртаклашалар, сөю-мәхәббәт хисләрен белдерәләр. Менә шуңа күрә дә дөньяда телдән дә яхшы бер нәрсә дә юк.



«Гомерем минем моңлы бер җыр иде»,- ди шагыйрь. Безнең өчен аның исеме дә җырга әверелде, республикабыз чикләрен үтеп, бөтен дөньяга яңгырады. Кешеләр аның тоткынлыкта, үләр алдыннан иҗат иткән шигырьләрен укып таң калды, аларны шагыйрьнең сынмас рухы, көче сокландырды.

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында
Янып калсын гомерең маяк булып,
Үзеңнән соң килгән буынга.

Муса Җәлилгә багышлап уздырылган кичә 6 нчы сыйныф укучылары күңелендә байтак сакланыр…

## Безнең Алия – җиңүче!

Алия дүртенче сыйныфның иң тырыш, иң үҗәт укучыларыннан берсе. Тырыш булмаса, ул бөтен республика күләмендә уздырылган олимпиадада шундый зур җиңүгә ирешә алмас та иде. Алия әледән-әле төрле ярышларда катнашып тора һәм район буенча нәтиҗәле урыннары да байтак. Укуы гел "5" кә генә булса да, грамоталарының саны үссә дә, Алия тормышта бик тыйнак кыз. Аны сыйныфташлары да бик хөрмәтлиләр, яраталар, аңардан үрнәк алалар. Чөнки ул үзе дә сыйныфташларына һәрвакыт ярдәм итәргә әзер тора. Укытучыларга да ул ныклы терәк. Чөнки аларның киңәшен тыңласа да, аның һәрвакыт үз фикере бар. Алия сау-сәламәт булсын, әйбәт укысын, гел яхшы нәтиҗәләргә ирешсен, эти-әнисенең терәге булып үссен, дигән матур теләктә калабыз без. Алия мәктәбебезнең исемен бик күп тапкырлар яхшы яктан яңгыратыр әле , менә күрерсез!




Алия Нуретдинова һәм аның укытучысы Резеда Галимова.

### Туган тел хакында

Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң:
"Әни!" - дип,
Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң:
"Әти!" – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң:
"Әни!" - дип,
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң:
"Әти!" – дип
Күзләреңә яшьләр тыгылыр –
Туган телең әнә шул булыр!
(Зөлфәт)

### КЕМ ЗИРӘК? ТАП ТИЗРӘК!!!

Хәрефләрен төшереп яки яңаларын кушып, мәгънәләрен үзгәртеп була торган табышмак сүзләр логогриф дип атала. Уйлап карыйк әле!

1. Минем барлык дүрт хәрефем
Төсне белдереп тора.
Мине хайван итеп була
Шуңа “К” өстәп кара.
2. Мине кулланалар йортта
Оннан икмәк басканда.
Алдыма бер “Ч” өстәсәң,
Ярыймын су ташырга
3. Бу сүзгә сатып алырсың
Теләгшән һәр нәрсәңне
Алдыма син “Б” өстәсәң
Җимеш бирермен бер мәлне.
4. Ял көннәре урамнарда
Уйнап мине атарсың.
Ахырына “Ы” өстәсәң,
Кулга китап тотарсың.
5. Мин – бер кеше исеме
Соңгы хәрефемне алсаң
Булам агач җимеше.

**Барлык җавапларны дөрес табучыга “5”ле!!! (чынлап)**

Шигъри почмак

**Әнием**ә **телә**гем.

Әнием – бердәнберем,
Бәйрәмең котлы булсын.
Алда яшисе көннәрең
Бәхет белән тулып торсын.
Һәр айларың көч куәт өстәп торсын,
Һәр елларың гөлләр кебек чәчәк атсын.
Син бит өебезнең кояшы дип саналасың,
Безнең өйне, күңелләрне нурландырасың.
Шул нур өчен сиңа, әни, бик зур рәхмәт.
Миннән сиңа тик бер теләк-
Насыйп булсын сиңа изге җәннәт!!!

*Ислам Сафиуллин 6 нчы сыйныф укучысы*

